МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.10.2016 Казан шәһәре № 338

**«Татарстан Республикасының елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» - бәйгесе җиңүчеләренә һәм призерларына грантлар бирү турында шартнамә формасын һәм гранттан файдалану турында финанс хисабын раслау хакында**

«Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика бәйгесе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасының елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» бәйгесе җиңүчеләренә һәм призерларына грантлар күчерү өчен **боерам:**

**1.** Расларга:

«Татарстан Республикасының елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» бәйгесе җиңүчеләренә һәм призерларына грантлар бирү турында шартнамәнең типлаштырылган формасын 1 нче кушымта нигезендә;

гранттан файдалану турында финанс хисабы формасын 2 нче кушымта нигезендә.

**2.** Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны икътисад министры урынбасары Н.А.Таркаевага йөкләргә.

Министр А.А. Здунов

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2016 елның 28 октябрендәге338 номерлы боерыгы белән расланды

***Типлаштырылган форма***

**«Татарстан Республикасының елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» бәйгесе җиңүчеләренә һәм призерларына грантлар бирү турында шартнамә**

_______ «__» ___ 201__ ел

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 23 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы турындагы Нигезләмә нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы икътисад министры Здунов Артём Алексеевич исеменнән Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык), бер яктан, һәм Устав нигезендә эш итүче муниципаль районның (шәһәр округының) башкарма комитеты (алга таба – вәкаләтле орган) исеменнән Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башкарма комитеты икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталучылар түбәндәгеләр турында әлеге шартнамәне (далее – Шартнамә) төзеделәр:

## 1. Шартнамә предметы

1.1. «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» бәйгесе йомгаклары буенча Вәкаләтле органга акча (алга таба – Грант) түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә күчерелә.

1.2. Грант «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика бәйгесе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы карары белән билгеләнгән нигездә һәм тәртиптә бирелә.

## 2. Грант бирү күләме һәм шартлары

2.1. Грант күләме _______ сум (сум).

2.2. Грант Вәкаләтле орган хисабына Татарстан Республикасы бюджетыннан күчерелә һәм Вәкаләтле орган тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарәнең (ТИҮ) устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга, ТИҮ рәисен һәм активын бүләкләүгә тотыла.

## 3. Министрлыкның хокуклары һәм бурычлары

3.1 Министрлык Вәкаләтле органның Шартнамә нигезендә үзенә йөкләнгән бурычларын үтәвен контрольдә тота.

3.2. Министрлык Вәкаләтле органнан Грантны куллануга кагылышлы финанс һәм башка документларны соратып алырга хокуклы.

3.3. Вәкаләтле орган алган Грантны сарыф итүгә кагылышлы документлар тапшырмаган очракта, грантны максатка ярашсыз сарыф иткән очракта, шулай ук дөрес булмаган яки ялган документлар биргән очракта, Министрлык Вәкаләтле органга Шартнамәне вакытыннан алда өзү турында хәбәрнамә җибәрү юлы белән Шартнамәне

берьяклы тәртиптә өзәргә хокуклы.

## 4. Вәкаләтле органның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Вәкаләтле орган Грант алырга хокуклы.

4.2. Вәкаләтле орган Грантны бары тик Шартнамәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән максатларда гына куллануны тәэмин итәргә тиеш.

4.3. Грантның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында, Вәкаләтле орган Министрлыкка хисап елыннан соң килә торган елның 1 июленә кадәр «Интернет» телекоммуникация челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында (http://mert.tatarstan.ru/) Министрлык тарафыннан урнаштырылган Министрлык тарафыннан расланган форма буенча Грантны куллану турында хисап тапшырырга тиеш.

4.4. Шартнамәнең 3.3 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне алганнан соң, Вәкаләтле орган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә Грант суммасын кире кайтарырга тиеш.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар закон нигезендә җаваплы.

5.2. Грантлар түләүгә бирелгән акчалар, Грант түләүгә бирелгән акчалардан максатка ярашсыз файдаланган һәм (яисә) дөрес булмаган хисап биргән очракта, Татарстан Республикасы бюджеты керемена 60 көн эчендә кайтарылырга тиеш.

Грантлар түләүгә бирелгән акчаларны кире кайтару срогы бозылганда, Министрлык әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 30 көн эчендә күрсәтелгән акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

5.3. Финанс хисабы елында Вәкаләтле орган тарафыннан файдаланылмаган Грант акчаларының калган акчалары булган очракта, Грант акчаларының калган өлешләре Татарстан Республикасы бюджеты керемена хисап чоры тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көнлек срокта кире кайтарылырга тиеш.

5.4. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары законнарда билгеләнгән тәртиптә Вәкаләтле органнар тарафыннан Грантлар түләүгә бирелгән акчаларны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерәләр.

5.5. Грантларны түләүгә бирелгән акчаларның максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын контрольдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.

## 6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Шартнамә имзаланган мизгелдән үз көченә керә һәм Яклар тарафыннан Шартнамә буенча барлык йөкләмәләре тулысынча үтәлгәнгә кадәр гамәлдә була.

6.2. Шартнамәгә теләсә нинди үзгәрешләр, өстәмәләр язма рәвештә төзелгән һәм Якларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган очракта гына гамәлдә була.

6.3. Шартнамә белән җайга салынмаган мөнәсәбәтләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җайга салына.

6.4. Шартнамә Якларның килешүе буенча, суд карары буенча яки Шартнамәдә каралган шартлар барлыкка килгән очракта вакытыннан алда өзелергә мөмкин.

6.5. Шартнамә буенча барлык бәхәсләр Яклар тарафыннан Министрлыкның урнашу урыны буенча судка мөрәҗәгать итү юлы белән хәл ителә.

6.6. Шартнамә тигез юридик көчкә ия 3 нөсхәдә төзелде, 2 нөсхәсе Министрлык өчен, 1 нөсхәсе Вәкаләтле орган өчен.

**7. Якларның адреслары һәм реквизитлары**

| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРЛЫК:** | **Вәкаләтле орган:** |
| 420021, ТР, Казан шәһәре, Мәскәү ур., 55 | |
| Банк Татарстан Республикасы Милли Банк Бүлеге Казан шәһәре | **Татарстан Республикасы ________________ муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты** |
| БИК 049205001 к/с-<br>р/с 40201810900000000002<br>алучысы: Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, ЛБ007020002-<br>МинЭкон))<br>ИНН 1655141501<br>КПП 165501001<br>ОГРН 1071690045129<br>ОКПО 82318720<br>ОКВЭД 75.11.21 | |
| **Татарстан Республикасы икътисад министры** | **Татарстан Республикасы ________________ муниципаль районы (шәһәр округы) Башкарма комитеты җитәкчесе** |
| ______________________**/Здунов А.А./** | ______________/__________/ |

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2016 елның 28 октябрендәге 338 номерлы боерыгы белән расланды

Форма

«Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» бәйгесе җиңүче һәм призеры тарафыннан Гранттан файдалану турында

**финанс хисабы**

Моның белән Башкарма комитетка грант бирү турында 201__ елның ___ _________ ____ номерлы Шартнамә нигезендә бирелгән Грантның территориаль иҗтимагый үзидарәнең (ТИҮ) устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга, ТИҮ рәисен һәм активын бүләкләүгә тотылуын раслыйм

| Территориаль иҗтимагый үзидарә исеме | Чаралар, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр исеме, аларны үткәрү вакыты, урыны һәм катнашучылар (башкаручылар) | Катнашучылар саны, кеше | Чаралар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрнең үтәлешен раслый торган документлар исеме һәм реквизитлары | Барлыгы, шул исәптән бюджеттан тыш акчалар, сум |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | БАРЛЫГЫ: |

Хисапка әлеге хисап мәгълүматларын раслый торган документларның тиешле рәвештә расланган күчермәләре һәм фотоматериаллар ___ биттә, ________ нөсхәдә теркәлә.

**Муниципаль район (шәһәр округы) Башкарма комитеты җитәкчесе – Вәкаләтле орган**

ФИА: Имза

«__»__________20 ______ел

Вәкаләтле органның – муниципаль районның (шәһәр округының) **Финанс-бюджет палатасы рәисе**:

ФИА: ____________ Имза ________________________________________

« » 20___ ел

**Муниципаль районның (шәһәр округының) территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесе**

| т/б № | Территориаль иҗтимагый үзидарә исеме | ФИА | Имза | Дата |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |